КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 21 ноябрь г.Казань № 1239

«Татарстан Республикасы Умартачылык һәм аквакультура үзәге» коммерциягә карамаган автоном оешмасын төзү турында

«Коммерциягә карамаган оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасында умартачылыкны һәм аквакультураны үстерү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының «Татарстан Республикасы Умартачылык һәм аквакультура үзәге» коммерциягә карамаган автоном оешмасы (алга таба – оешма) төзү турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына:

оешманың гамәлгә куючысы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашырырга;

30 көн эчендә оешма уставын расларга;

оешманы дәүләт теркәвенә алуны законнар белән билгеләнгән тәртиптә тәэмин итәргә;

оешма төзүгә бәйле башка чараларны үткәрергә.

3. Оешма төзегәндә гамәлгә куючы тарафыннан 2023 елның 30 апреленә кадәр Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 10,0 мең сум күләмендә ихтыяри мөлкәт кертеме кертелә дип билгеләргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин